Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам Нуры

№ 21 (649) 13 ноябрь, 2017 ел (1439, Сәфәр) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

## Дәүләтнең көче – бердәмлектә

Мәскәүдә Зур Кремль сараенда Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан Россия Президенты В.В.Путинның тантаналы кабул итү кичәсе булды. Чакырылган кунаклар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм аның урынбасары, Болгар ислам академиясе һәм Россия ислам институты ректоры Рәфыйкъ Мөхәммәтшин да булдылар. Шулай ук чарада Болгар ислам академиясе президенты Камил Исхаков һәм КФУның Филология һәм мәдәниятләр арасында багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов та катнашты.

Узган җомга намазларында Татарстанның барлык мәчетләрендә дә дәүләт бәйрәменә — Халыклар бердәмлеге көненә багышланган вәгазьләр укылды.

“Безнең илебез — күп милләтле, күп динле. Шуның өчен һәр дәүләтнең киләчәге халыкара дуслык, бердәмлек, татулыкка бәйле. Әгәр дә халык дуслык-татулыкны югалтса, киләчәк юк дигән сүз. Ислам дине — кешеләрне берләштерә торган дин ул”, - диелде әлеге вәгазьләрдә.



## Укулар узды



*Рөстәм хәзрәт Мәскәүдә*

Мәскәүдә X халыкара теологик конференция — Галимҗан Баруди исемендәге укулар уздырылды. Анда Чаллының “Ак мәчет” мәдрәсәсе директоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев дә катнашты.

## Чаллылар – җиңүчеләр!

28 нче октябрьдә Алабуга шәһәренең физкультура-сәламәтләндерү комплексында мини-футбол, кул көрәше, бау тартышу һәм гер күтәрү буенча спорт ярышлары узды. Анда бары тик намаз укучы һәм профессиональ спорт белән шөгыльләнмәгән мөселман яшьләре генә катнаша алды. Чаллы мөселман яшьләре кул көрәшендә I һәм II, ә мини-футбол буенча III урыннарны отып кайтты.



*Мөселман яшьләре*

## Мөгаллимнәр өчен бәйрәм

27 октябрьдә Чаллының “Хәләл Үзәге”ндә гадәти булмаган чара — “Дини белем мәҗлесе” узды. Анда шәһәр имамнары, мәчетләрнең уку-укыту өчен җаваплы хезмәткәрләре, мәчетләрнең аксакаллар шурасы рәисләре, якшәмбе мәктәбе укытучылары катнашты. Мәҗлес бүгенге көн өчен бик мөһим мәсьәлә — татар телен саклап калу, мәчетләрдә татар мохитен көчәйтү турында сөйләшүдән башланды. Бу темага шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин эчтәлекле вәгазь сөйләде. Мөхтәсибәтнең уку-укыту буенча җаваплы хезмәткәре Илназ хәзрәт Яхинның да чыгышы күбрәк туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклауга юнәлдерелде. Чыгышлардан соң якшәмбе мәктәпләренә иң күп укучылар җыйган мәчетләр һәм укытучылар билгеләнде, аларга “Хәләл-Үзәк”нең 5, 3, 2 мең сум күләмендәге сертификатлары һәм мөхтәсибәтнең Рәхмәт хатлары тапшырылды. Мондый хөрмәткә шәһәрнең “Ак мәчет”е, “Нур-Ихлас”, “Ихлас” мәчетләре, ирләр төркемнәре укытучылары Рамил хәзрәт Мозаффаров (“Ак мәчет”), Илназ хәзрәт Яхин (“Ихлас”), Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев (“Тәүбә”), хатын-кызлар төркемнәре укытучылары Рәвия абыстай Илалова, Камилә абыстай Тулбаева, Роза абыстай Фәрхетдинова (өчесе дә “Ак мәчет”тән), балалар төркемнәре укытучылары Али хәзрәт Баһаветдин (“Әбүзәр”), Гөлназ



абыстай Габделхакова (“Ихлас”), Илмир хәзрәт Гаязов (“Тәүбә”) лаек булдылар. Ә иң актив мөгаллимә дип табылган һәм берничә уку әсбабы авторы булган Рәвия абыстай Зиярова га (“Хәләл-Үзәк” җитәкчесе Илдар хәзрәтнең җәмәгате) мөхтәсибәт әзерләгән махсус бүләк тапшырылды. Аттестация узган укытучыларга Дания нәзарәте бүләге — “Ислам дине нигезләре” китабы, ә мәчетләргә Илдар хәзрәт һәм Рәвия абыстай әзерләгән уку әсбаблары таратылды.

Мәҗлес ахырында анда катнашучылар тәмле пылау, кайнар чәй белән сыйландылар. Мөгаллимнәр өчен оештырылган ошбу бәйрәм файдалы да, күңелле дә булып үтте.

**Хәлил Шәрипов.**

# Туган телебезне саклыйк!

*Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, безне төрле милләтләр итеп яралткан, төрле нигъмәтләр белән бүләкләгән Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз һәм олуглауларыбыз булса иде. Барча пәйгамбәрләрнең имамы булган, безгә мәңгелек бәхеткә илтүче юлны өйрәтеп калдырган расүлебез – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәсәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.*

Соңгы вакытта татар телен саклау турында күп сөйләшүләр бара. Кызганычка, кайбер кардәшләребез туган телебезгә битарафлык күрсәтәләр, татар телен белү нәрсәгә кирәк, диләр. Туган телгә шундый мөнәсәбәт бай тарихыбызны, тамырларыбызны, рухи мирасыбызны белмәүдән килә. Ә бит газиз халкыбыз гаять бай рухи хәзинә тудырган, гомумкешелек мирасына үзеннән зур өлеш керткән. Шунысын белергә кирәк: мең ярым еллык язма әдәбияты булган халыклар дөньяда бик сирәк! Бабаларыбыз безнең эраның бишенче гасырларында ук үз алфавитларын булдырганнар, унынчы гасырдан алып егерменче гасырның 20 нче елларына кадәр, ягъни мең елдан артык гарәп язуын кулланганнар. Туган телебездә олуг галимнәребез диннең төрле фәннәре (гакыйдә, фикһ, тәҗвид, сира, әхлак h.б.) буенча китаплар язып калдырганнар, бөек шагыйрьләребез, язучыларыбыз бик матур әдәби әсәрләр иҗат иткәннәр. Шуңа күрә танылган галим Миркасыйм Госманов (1934-2010) әйткән: "Халыкның милли йөзен, милли рухын, милли төсмерен билгеләүче әйбер була һәм татарларда ул, иң беренче чиратта, китаплылык".

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә "Хөҗурат" сүрәсенең 13нче аятендә болай дип әйтә: **"Әй кешеләр! Хактыр ки, Без сезне бер ир һәм хатыннан яралттык. Бер-берегезне өйрәнер өчен, сезне халыклар һәм кавемнәргә (милләтләргә) аердык. Аллаһ каршында иң хөрмәтлегез Аллаһтан (Аның җәзасыннан) куркып, гөнаһлар кылудан саклануычыгыздыр. Дөреслектә, Аллаһ барысын да белеп, барысыннан да хәбәрдар булып тора".**

Милли үзенчәлекләрне, телебезне, гореф-гадәтләребезне сакламасак, бер-беребезне ничек таныйрбыз? Милләтләр кирәк булмаса, Аллаһ аларны яралтмас, аятьләре белән әһәмиятен дә аңлатмас иде. Милли үзенчәлекләрне, шул исәптән туган телебезне санга сукмау Аллаһка каршы килү була. Туган телебезне өйрәнү, белү һәркайсыбыз өчен тиешле гамәл. Балаларыбызга дини тәрбия белән бергә милли тәрбия дә бирү зарур. Әмма милли тәрбия, милли аң, милли горурлык башка халыкларны кимсетү хисабына булырга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә "Хөҗурат" сүрәсенең 11нче аятендә болай дип әйтә: **"Әй мөэминнәр! Бер кавем икенче кавемне кимсетмәсен, ул кимсетелгән кавемнең кимсетүче кавемнән яхшырак булуы ихтимал".** Йә гарәп, йә төрек, йә урыска охшарга тырышып, үз милләтебезгә, туган телебезгә кимсетеп карасак, әлеге аятькә каршы килүчеләр булмабызмы? Шул ук вакытта башка бер милләтне кимсетеп карау да дөрес түгел. Аллаһы Раббыбыз бу аятьтә: "Әй мөэминнәр!" дип эндәште, димәк, иманлы кеше үз милләтенә дә түбәнсетеп карамас, башка милләтне дә хөрмәт итәр.

Телебезне, гореф-гадәтләребезне белмәү, өйрәнмәү безне рухи яктан зәгыйфьләндерә, ярлыландыра, динебездән ваз кичүгә дә китерергә мөмкин.

Бөек галимебез Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗәни (1818-1889) әйткән: "Өч төрле әйбер диндә булмаса да, динне саклый, алар: милли тел, милли кием һәм милли гореф".

Татар телебез искиткеч матур һәм камил. Аны өйрәнүгә омтылырга кирәк. Туган телебезне яхшы белсәк, рухи мирасыбызны, бай мәдәниятебезне өйрәнә алачакбыз, башка төрки телләрне аңлаячакбыз. Гаиләләребез, туган-тумачаларыбыз һәм дин кардәшләребез белән ана телебездә аралашыйк. Хаталар булса да, рус сүзләре кушылса да, туган телебездә сөйләшик. Никадәр күбрәк сөйләшсәк, телебез шулкадәр яхшырак, камилрәк булыр.

Аллаһы Тәгалә барчабызга динебезне, туган телебезне, милли үзенчәлекләребезне саклап, изгелекләр кылып, ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирешергә насыйп итсен!

**ТР МДНнең дәгъват бүлеге.**

## СОРАУ-ҖАВАП

Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга шәригать белгече **Рәфыйк хәзрәт Миннәхмәтов** җавап бирә:

**– "Ислам нуры" газетасын инде 6 ел яздырып укыйбыз, мәчеткә дә яздырдык. Газетадан укып, корбанлык хайванның йонын кыркырга ярамаганлыгын белдек, печтерелгән тәкәнең корбанлыкка ярaганлыгын аңладык. Без корбан өчен Романов токымы сарыклары үрчетәбез. Буаз сарыклар корбанлыкка ярыймы икән? Башлангыч чорында аларның буаз булуын билгеләве бик авыр. Буаз булып чыксалар, без гөнаһлы булмыйбызмы?**

**Сәҗидә һәм Ингел Галимуллиннар,**
**Менделеевск районы Татар Сарсазы авылы.**

– Буаз малларны корбанлыкка чалырга ярамый дигән хөкем юк. Аларны ит өчен дә, корбанлыкка да чалу рөхсәт ителә. Чалган вакытта бәрәне яки бозавы булып, ул тере икән, аны да бисмилла әйтеп чалырга, итен ашарга мөмкин, ул хәләл була. Үле булса – инде үләксә санала.

– Кеше туган җиреннән читтә вафат булса, җирләргә үз авылына алып кайткач, җәсәден туган нигезенә, ишегалдына кертү мәҗбүри гамәлме?

**Кәүсәрия Сәүбәнова,**
**Актаныш районы Качкын авылы.**

– Динебез буенча, кеше кайда вафат була – шунда җирләнергә тиеш, туган ягына алып кайтырга дигән шарт юк. Вафат булган җирендә мөселман зираты юк икән инде, еракта булса да, мөселман зиратына алып бару кирәк. Юылган, җеназасы укылган икән, мәетне тегендә-монда йөртү түгел, ашыктыру хәерле.

## МИНЕМ ФИКЕР



**"Ихлас" мәчете имам-хатыйбы Илназ хәзрәт Яхин:**

Авылда бер әби көянтә белән су ташый икән. Бераз бара да утырып ял итә, бераз бара да утырып ял итә. Бер егет, әбине кызганып, көянтәне күтәрә дә өенә илтә. Шулвакыт әбигә сорау бирә: "Әби, сезнен балаларыгыз юк мени?" Әби: "Бар балаларым. Үстеләр. Бай булуларын теләдем – бай булдылар. Сәламәт булуларын теләдем – сәламәт булдылар. Иман теләргә онытканмын икән – имансыз булдылар", – дип җавап бирә. Кызганычка, халкыбыз «иман», «әхлак», «тәүфыйк» дигән сүзләрнен хәтта мәгънәсен дә онытты. «Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми», диелә халкыбыз мәкалендә. Баланы бишектән тәрбияләү кирәк. Бүген балалар хәтта курчак белән дә уйнамый. Планшет яки телефон белән уйнап тәрбияләнә.

*Безгә язалар*

## Изге теләк юллыйбыз

Әссәләмүгаләйкүм!

Хөрмәтле "Ислам нуры" газетасы хезмәткәрләре, без сезнең газетаны 1998 елдан бирле укып барабыз, үзебезгә кирәкле бик күп дини мәгълүматлар алабыз. Сезнең газетаны көтеп алып, мәчеттә булсын, Коръән мәҗлесендә булсын, кумәкләп укыйбыз. Сезгә шушы эшләрегез өчен зур рәхмәт! Аллаһы Раббыбыз сезгә иксез-чиксез әҗер-савапларын бирсен. Сезгә хат язуыбызның төп сәбәбе: быел Рамазан уразасын изге Мәккә, Мәдинә шәһәрләрендә тотарга насыйп булды. Бу кече хаҗның бөтен йолаларын (тәртипләрен) дөрес итеп үтәргә җитәкчебез Марат хәзрәт Бикбаев ярдәм итте. Ул көн дә безнең хәлләребезне белешеп, авырып китсәк — даруларын табып, кыскасы, бөтен мәшәкатьләребезне үз өстенә алып, безне бер ай җитәкләп йөртте дисәк тә дөрес булыр. Без абыстаем белән бишенче тапкыр хаҗ кылдык, әмма Марат хәзрәт кебек җитәкчебез булмады дисәм дә хаталанмам. Үзебез һәм группабыз — барысы 21 кеше исеменнән Марат хәзрәткә сезнең газета аша бик күп рәхмәтләребезне белдерәбез. Алдагы көннәрдә дә аның үзенә, гаиләсе, балаларына исәнлек-саулык һәм күп-күп изгелекләр эшләп, Аллаһы Раббыбызның әҗер-савапларын алып, эшеннән, гаиләсеннән тынычлык, канәгатьлек табып, озын-озак гомерләр яшәргә насыйп булсын.

**Оренбург өлкәсе, Әсәкәй районы Иске Мөэмин авылы имам-хатыйбы**
**Камил хаҗи һәм хаҗия Саимә абыстай Нәфыйковлар.**

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән*

# Йөрәк бабай һәм падишаһ

*(Хикәят. Төрекчәдән Фатих Кутлу тәрҗемәсе. Дәвамы)*

ҖАҺИТ ЗАРИФОГЛУ

Тау башында кояш чыкканчы кешеләр ничек уянганнар икән? Бер гади сәгать тә, шалтыраучы сәгать тә булмаган. Уятучы да, сакта торучы да юк. Кояш ястүдән соң 5 сәгатьтән, я 10 сәгатьтән чыга. Кояшның чыгуы ел фасылыннан ел фасылына үзгәрә. Ә үзгәрмәсә, организм билгеле бер вакытта торырга иялләшкән бит, дип әйтер идек. Ләкин бер фасыл кояш сәгать 4тә, бер фасыл тугызынчы яртыда чыга.

Һәр иртәне, кояш чыгарга бер сәгать калгач, Йөрәк бабай күзләрен ача, Айшә әби рәхәтләнеп йоклый икән. Иллә мәгәр Йөрәк бабай уятып савапка керәсе килә икән. Әгәр шактый вакыт үтеп тә, кояш чыгарга бер чирек вакыт калгач Йөрәк бабай һаман уянмаса, бу юлы күзләрен Айшә әби ача да тиз генә:

— Ай Аллам, бәй! Соңга калабыз! Озакламый кояш чыга, - дигәч, кабаланып торып, намазга басалар.

Озакламый намаз тәмам. Йөрәккә тагын бер ялтыравык атыла я караш юешләнә. Шул рәвешле, Аллаһның боерыгы, бәндәнең теләге белән барган гыйбадәт, күз яше, ялвару, бөеклек, хикмәт һәм эре күз яшьләре белән чылатылган кебек почмаклары, утта кыздырылган бер тимер поднос шикелле кояш. Җир авызын ачкан, кошлар ук кебек һавага атылган. Дөя торып, чирәмлектә йөри башлаган. Ул әйләнеп шәһәр ягына карый икән.

Тегендә, чатыр янында, бисмилла әйтеп аш ашыйлар. Гүя ашның да җаны бар. Гүя түксәң, рәнҗер, савытта калдырсаң, үпкәләр сыман.

— Хатынкаем, әйберләрне иртәрәк төяп, тауга таба барыйкмы, әллә монда бер-ике көн юанып, вакыт үткәрикме, ни әйтерсең? — дип сораган Йөрәк бабай.

— Син ничек теләсәң, шул булыр.

— Һыммм, алай булгач, тагын бер көнгә калыйк әле, - диде Йөрәк бабай. — Бу кичтә дә әнә шул шәһәрнең утларын карыйк әле. Мине ул утлар үзенә шулкадәр җәлеп иткәнен, уйландырганын белсәң иде...

Шәһәрнең кичен җемелдәп янган утлары карт кешене ни турында уйландырды икән? Ни турында сөйләгән Йөрәк бабай, нинди уйланулар турында әйткәне безгә билгесез, анысы сер. Тыңлыйк әле, бу сөйләшүнең ахыры ничек төгәлләнгән икән?

— Бераз йөреп, чишмә башын табыйкмы, җанашым? Әллә, суыбыз җитәр дип, монда калыйкмы?

— Ничек телисең. Теләсәң, мин барып бер карап килим. Син интекмә, сәфәр юлдашым, дөньядагы иптәшем.

— Ул нинди сүз тагын, ханым? Аллаһтан теге дөньяда икебезнең бергә булуын телим мин.

— Аһ, Аксакалым, анда сиңа ни кирәгем бар, яшем шактый, күрәсең. Пәйгамбәр Әфәндебезнең җәннәткә карт хатыннар кермәячәк дигәнен беләсең.

— Бу сүзне ул кемгә әйткән?

— Карт бер хатынга.

— Хатын нишләгән?

— Борчылган.

— Соңыннан Әфәндебез нәрсә әйткән?

— Борчылганын күргәч, өстәп куйган: "Чөнки анда ирләр яки хатын һәммәсе яшь-яшь булып керәчәк", - дигән.

— Шулай булгач. Алла бирсә, син дә, мин дә җәннәткә кереп яшь-яшь булачакбыз, ә?

— Шулай да, хур кызлары була торып...

— Әллә син, тегендә күчмәс борын, хур кызларыннан көнләшә башладыңмы?

— Аһ, әфәндем! Ничек дип әйтим, көнләшмим дисәм, зур ялган булыр.

Йөрәк бабай кеткелдәп көлде.

— Сиңа бер нәрсә әйтимме? — диде.

— Боер, - диде Айшә әби, - боер, эшлим.

— Хатынкаем! Мин дә сиңа әйтергә дип йөри идем: күптән миннән бер әйбер дә сорамыйсың. Ни кушсаң, шуны эшлим. Син куш, мин эшлим.

— Ай, әфәндем, бу нинди сүз, мин синең аягың астында җир булыйм. Боерык бир, үземне юлыңа корбан итим.

— Ай, күземнең нуры! Солтаным! Бу ниди сүз инде?

— Син мине кызартасың, оялтып бетерәсең

— Мин синең әмереңне ишетергә телим.

Сүз яңадан назга, нәзакатьле сүзләргә кайтып калган. Әмма соңыннан Йөрәк бабай шуны аңлаган ки, озак еллар инде хатыны үз гомерен тулысы белән иренә хезмәт итүгә багышлаган, әгәр берәр теләге була калса, аны бары Аллаһтан гына сораячак. Ул теләгәнне Аллаһ, әгәр Йөрәк бабайның күңеленә салса, булыр, салмаса, булмас икән. Айшә әби анысына да, монысына да риза.

— Бусы да нечкә бер эш, - диде эченнән генә Йөрәк бабай. — Монда да бер үзенчәлек бар. Яши-яши безнең хатын әүлияга әверелә. Һәм бусы да күз алдында була, мин генә сизмим, ахры.

Кояш кичкә авыша башлаган. Менә шул мизгелдә Йөрәк бабай, хатыны Айшә әби һәм дөякәй еракларддан тауга таба килүчеләрне күреп алганнар: бертөркем атлылар килә икән.

— Менә нинди шатлык! — дигән Йөрәк бабай хатынына.

— Менә нинди шатлык! — дигән Айшә әби. — Шөкерләр булсын кунак җибәрүче Раббыбызга!

Үзләрен каршы алыр өчен ашыга-ашыга атлап килгән Йөрәк бабайга:

— Әссәламугаләйкум, - диде атлыларның беренчесе.

- Вәгаләйкумәссәлам! Хуш килдегез!

***(Дәвамы бар)***

**ӘДӘБИ СҮЗ**

*Рифат Сәлах*

## Йә Аллаһым!..

*Йә Аллаһым!*
*Кичер мине, кичер.*
*Догаларым кабул кылсаң икән!*
*Аз ялвардым сиңа.*
*Артык иртә*
*Китәм бугай Рәхмәт үзәненнән.*

*Иртәм китәм.*
*Әйе, артык иртә.*
*Кылып бетмәс инде бөтен догам.*
*Күңелемә ут бир, ләкин сакла*
*Йә Ходаем, тәмуг утларыннан!*

*Йә Аллаһым!*
*Тагын бер кат кичер*
*Бәрәкәтле үтмәсә бу көнем.*
*Әгәр әмер итсәң,*
*Гарәфәнең*
*Үзәнендә мәңге калыр идем.*
*Иртә әле,*
*Әйе, бөтен догам*
*Өзелмәде әле үзәгемнән.*
*Мәңгелеккә диеп саубуллашып*
*Китә алмам Рәхмәт үзәненнән!*

## Гыйбадәт

*Аллаһ исме белән башлыйм әле! –*
*Изге эшләр шулай башлана*
*Һәм күкләргә багып дога кылам:*
*«Йә Ходаем, үзең ташлама!»*

*Һәм диварга килеп башны куям,*
*Кулны куям дивар өстенә.*
*Бер үрмәкүч пәрәвезен үргән –*
*Язып куйган сыман "бисмилләһ".*

*Маңгаемны җир өстенә куям*
*Һәм ялварып сорыйм, тезләнәм.*
*Мин булмасам иде язмышымның*
*Бәхет-сынавына түзмәгән.*

*Һәм күкләргә багып дога кылам,*
*Йә Ходаем, үзең ташлама!*
*...Гаҗәпләнәм, әле шуннан соң да*
*Бәгыремдә күпме таш кала.*

## Хөсетлек

Елан, үтерү нияте белән, бер күбәләкне аулый башлый. Күбәләк исә еланнан котылу өчен бер җирдән икенче җиргә качарга тырыша. Шулай итеп бу хәл берничә көн дәвам итә. Иң соңыннан күбәләк еланнан:

— Синнән котылып булмас, ахрысы. Рөхсәт итсәң, мине үтерер алдыннан сиңа берничә сорау бирергә телим, - дип сорый.

Елан пышылдый-пышылдый гына:

— Әйе, тыңлыйм сине, - дип әйтә.

— Син күбәләкләр белән тукланасыңмы? — дип сорый күбәләк.

— Юк, - дип җавап кайтара елан.

— Мин сиңа берәр нинди начарлык эшләдемме әллә?

— Юк!

— Алай булгач, мине ни өчен үтермәкче буласың?

— Синең тирә-якка матурлык чәчеп очып йөрүеңне күрергә теләмим, - дип җавап кайтара елан.

Хөрмәтле дустым! Бу хикәядәге елан — хөсетле кешене аңлата. Хөсетлек исә иң начар җан авыруларыннан санала. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хөсетләнүчеләрне Аллаһның дошманнары дигән. Чөнки алар Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә биргән нигъмәтләренә каршы хөсетлек итәләр.

**("Бәхетлеләрнең серләре" китабыннан)**

## Колак салсаң – үкенмәссең

- Намазда булсаң – йөрәгеңне сакла.
- Кешеләр җыелган урында булсаң – телеңне сакла.
- Чит өйдә булсаң – күзеңне сакла.
- Табын алдында булсаң – ашказаныңны сакла.
- Ике нәрсәне онытып, беркайчан да искә алма: үзең кылган изгелекне һәм сиңа эшләнгән явызлыкны.

# Намаз вакытлары

| Милади Декабрь | Көн исеме | Раб. әүвәл Раб. ахир | Иртәнге намаз | | | | | | Кояш чыга | | | Зәвәл | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ястү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Таң беленә | | | Мәчетләрдә укыла | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Жм | 12 | 07.01 | 05.17 | 05.31 | 07.44 | 06.04 | 06.17 | 09.14 | 07.34 | 07.47 | 13.04 | 11.19 | 11.32 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.06 | 13.15 | 13.28 | 16.54 | 15.03 | 15.16 | 18.45 | 16.58 | 17.11 |
| 2 | Шм | 13 | 07.02 | 05.19 | 05.32 | 07.46 | 06.06 | 06.19 | 09.16 | 07.36 | 07.49 | 13.04 | 11.19 | 11.32 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.05 | 13.14 | 13.27 | 16.53 | 15.02 | 15.15 | 18.44 | 16.57 | 17.10 |
| 3 | Як | 14 | 07.04 | 05.20 | 05.33 | 07.47 | 06.07 | 06.21 | 09.17 | 07.37 | 07.51 | 13.05 | 11.20 | 11.33 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.04 | 13.13 | 13.26 | 16.52 | 15.01 | 15.14 | 18.44 | 16.56 | 17.10 |
| 4 | Дш | 15 | 07.05 | 05.21 | 05.34 | 07.49 | 06.09 | 06.22 | 09.19 | 07.39 | 07.52 | 13.05 | 11.20 | 11.33 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.04 | 13.13 | 13.26 | 16.51 | 15.01 | 15.13 | 18.44 | 16.56 | 17.09 |
| 5 | Сш | 16 | 07.06 | 05.22 | 05.35 | 07.50 | 06.10 | 06.24 | 09.20 | 07.40 | 07.54 | 13.05 | 11.20 | 11.33 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.03 | 13.12 | 13.25 | 16.51 | 15.00 | 15.13 | 18.43 | 16.55 | 17.09 |
| 6 | Чш | 17 | 07.07 | 05.23 | 05.37 | 07.52 | 06.12 | 06.25 | 09.22 | 07.42 | 07.55 | 13.06 | 11.21 | 11.34 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.03 | 13.12 | 13.24 | 16.50 | 14.59 | 15.12 | 18.43 | 16.55 | 17.08 |
| 7 | Пҗ | 18 | 07.08 | 05.25 | 05.38 | 07.53 | 06.13 | 06.27 | 09.23 | 07.43 | 07.57 | 13.06 | 11.21 | 11.34 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.02 | 13.11 | 13.24 | 16.50 | 14.59 | 15.12 | 18.43 | 16.55 | 17.08 |
| 8 | Жм | 19 | 07.09 | 05.26 | 05.39 | 07.54 | 06.15 | 06.28 | 09.24 | 07.45 | 07.58 | 13.07 | 11.22 | 11.35 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.02 | 13.11 | 13.24 | 16.49 | 14.58 | 15.11 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 9 | Шм | 20 | 07.10 | 05.27 | 05.40 | 07.56 | 06.16 | 06.29 | 09.26 | 07.46 | 07.59 | 13.07 | 11.22 | 11.35 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.02 | 13.10 | 13.23 | 16.49 | 14.58 | 15.11 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 10 | Як | 21 | 07.11 | 05.28 | 05.41 | 07.57 | 06.17 | 06.31 | 09.27 | 07.47 | 08.01 | 13.08 | 11.22 | 11.36 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.49 | 14.58 | 15.10 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 11 | Дш | 22 | 07.12 | 05.29 | 05.42 | 07.58 | 06.18 | 06.32 | 09.28 | 07.48 | 08.02 | 13.08 | 11.23 | 11.36 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 12 | Сш | 23 | 07.13 | 05.30 | 05.43 | 07.59 | 06.20 | 06.33 | 09.29 | 07.50 | 08.03 | 13.09 | 11.23 | 11.37 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 13 | Чш | 24 | 07.14 | 05.31 | 05.44 | 08.01 | 06.21 | 06.34 | 09.30 | 07.51 | 08.04 | 13.09 | 11.24 | 11.37 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 14 | Пҗ | 25 | 07.15 | 05.31 | 05.45 | 08.02 | 06.22 | 06.35 | 09.31 | 07.52 | 08.05 | 13.10 | 11.24 | 11.37 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 15 | Жм | 26 | 07.16 | 05.32 | 05.45 | 08.03 | 06.23 | 06.36 | 09.32 | 07.53 | 08.06 | 13.10 | 11.25 | 11.38 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.42 | 16.55 | 17.08 |
| 16 | Шм | 27 | 07.17 | 05.33 | 05.46 | 08.04 | 06.24 | 06.37 | 09.33 | 07.54 | 08.07 | 13.11 | 11.25 | 11.38 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.43 | 16.55 | 17.08 |
| 17 | Як | 28 | 07.17 | 05.34 | 05.47 | 08.05 | 06.24 | 06.38 | 09.34 | 07.54 | 08.08 | 13.11 | 11.26 | 11.39 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.01 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.43 | 16.55 | 17.08 |
| 18 | Дш | 29 | 07.18 | 05.35 | 05.48 | 08.06 | 06.25 | 06.39 | 09.35 | 07.55 | 08.09 | 13.12 | 11.26 | 11.39 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.02 | 13.10 | 13.23 | 16.48 | 14.57 | 15.10 | 18.43 | 16.56 | 17.09 |
| 19 | Сш | 1 | 07.19 | 05.35 | 05.48 | 08.07 | 06.26 | 06.39 | 09.35 | 07.56 | 08.10 | 13.12 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.02 | 13.11 | 13.23 | 16.49 | 14.57 | 15.10 | 18.44 | 16.56 | 17.09 |
| 20 | Чш | 2 | 07.20 | 05.36 | 05.49 | 08.07 | 06.27 | 06.40 | 09.36 | 07.57 | 08.11 | 13.13 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.02 | 13.11 | 13.24 | 16.49 | 14.58 | 15.11 | 18.44 | 16.56 | 17.09 |
| 21 | Пҗ | 3 | 07.20 | 05.36 | 05.50 | 08.08 | 06.27 | 06.41 | 09.37 | 07.57 | 08.12 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.03 | 13.11 | 13.24 | 16.50 | 14.58 | 15.11 | 18.44 | 16.57 | 17.10 |
| 22 | Жм | 4 | 07.20 | 05.37 | 05.50 | 08.08 | 06.28 | 06.41 | 09.37 | 07.58 | 08.12 | 13.14 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.03 | 13.12 | 13.25 | 16.50 | 14.59 | 15.12 | 18.45 | 16.57 | 17.10 |
| 23 | Шм | 5 | 07.21 | 05.37 | 05.51 | 08.08 | 06.28 | 06.42 | 09.38 | 07.58 | 08.12 | 13.14 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.04 | 13.12 | 13.25 | 16.51 | 14.59 | 15.12 | 18.45 | 16.58 | 17.11 |
| 24 | Як | 6 | 07.21 | 05.38 | 05.51 | 08.08 | 06.29 | 06.42 | 09.38 | 07.59 | 08.13 | 13.15 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.04 | 13.13 | 13.26 | 16.51 | 15.00 | 15.13 | 18.46 | 16.58 | 17.11 |
| 25 | Дш | 7 | 07.22 | 05.38 | 05.51 | 08.08 | 06.29 | 06.42 | 09.39 | 07.59 | 08.13 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.05 | 13.13 | 13.27 | 16.52 | 15.01 | 15.13 | 18.47 | 16.59 | 17.12 |
| 26 | Сш | 8 | 07.22 | 05.39 | 05.52 | 08.09 | 06.30 | 06.43 | 09.39 | 07.59 | 08.13 | 13.16 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.06 | 13.14 | 13.27 | 16.53 | 15.02 | 15.14 | 18.47 | 17.00 | 17.13 |
| 27 | Чш | 9 | 07.22 | 05.39 | 05.52 | 08.09 | 06.30 | 06.43 | 09.39 | 07.59 | 08.13 | 13.16 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.07 | 13.15 | 13.28 | 16.53 | 15.03 | 15.15 | 18.48 | 17.01 | 17.13 |
| 28 | Пҗ | 10 | 07.23 | 05.39 | 05.52 | 08.09 | 06.30 | 06.43 | 09.39 | 08.00 | 08.13 | 13.17 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.07 | 13.16 | 13.29 | 16.54 | 15.04 | 15.16 | 18.49 | 17.02 | 17.14 |
| 29 | Жм | 11 | 07.23 | 05.39 | 05.52 | 08.09 | 06.30 | 06.43 | 09.39 | 08.00 | 08.13 | 13.17 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.08 | 13.17 | 13.30 | 16.55 | 15.05 | 15.17 | 18.50 | 17.03 | 17.15 |
| 30 | Шм | 12 | 07.23 | 05.39 | 05.53 | 08.09 | 06.30 | 06.43 | 09.39 | 08.00 | 08.13 | 13.18 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.09 | 13.18 | 13.31 | 16.56 | 15.06 | 15.18 | 18.50 | 17.04 | 17.16 |
| 31 | Як | 13 | 07.23 | 05.39 | 05.53 | 08.09 | 06.29 | 06.43 | 09.39 | 07.59 | 08.13 | 13.18 | 11.33 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.10 | 13.19 | 13.32 | 16.57 | 15.07 | 15.19 | 18.51 | 17.38 | 17.17 |

## Көз сагышы

*Көзге урман алтын төсен инде җуйган,*
*Бөтен җиһан, кышны көтеп микән, тынган.*
*Көзге төсләр уңган, сулган, ямен җуйган,*
*Нечкә күңел көзге сагыш белән тулган...*

*Кар яудырып, бераз безне сынап алгач,*
*Кыш сафлыгы күңелләргә коткы салгач,*
*Елак болыт шәлен иңнәренә кире салган,*
*Көз сагышы тамчы булып җиргә тамган...*

*“Алтын кулмәгемне салгач, шыксызмыни?*
*Шуны аңлап елыйм ич мин... кызган мине!*
*Агачтагы яфрак хәтта сизгән халәтемне,*
*Җиргә төшми, көтә соңгы сәгатемне”.*

*Көз сагышы, көз болыты, көзнең җиле,*
*Көз яфрагы, көз иртәсе, көз күңеле...*
*Аңлаганчы синең тирән сагышыңны,*
*Күз яшьләрең әле озак түгелерме?*

**Энҗе Нурисламова, Чаллы**



**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен: e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 13 ноябрь 16 сәг. фактта 13 ноябрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**